СОВЕТ БОЛЬШЕМЕМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ОЛЫ МЕМИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ
23.10.2018

КАРАР
№ 47-215

с. Большие Меми

«Югары Ослан муниципаль районының Олы Мәми авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында" Олы Мәми авыл җирлеге Советының 2016 елның 24 апрелендәге 36-168 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

"Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары белән расланган "Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында" 2018 елның 17 октябрендәге 940 номерлы карары, Югары Ослан муниципаль районының Олы Мәми авыл җирлеге Уставы нигезендә

Югары Ослан муниципаль районы
Олы Мәми авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. “Югары Ослан муниципаль районының Олы Мәми авыл җирлегенең «Югары Ослан муниципаль районының Олы Мәми авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының даими нигездә үз вәкаләтләрен башкаручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарның нормативлары турында» 2018 елның 24 апрелендәге 36-168 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның икенче абзацында «4.65» санын «6,72» санына алмаштырырга

2. Әлеге карар 2018 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан районының Олы Мәми авыл җирлеге Советының социаль-мәдәни һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе
Югары Ослан муниципаль районы
Олы Меми авыл җирлеге башлыгы Г.А. Фомина